КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 9 декабрь г.Казань № 1124

Татарстан Республикасы территориясендә гидротехника корылмасы һәлакәте аркасында физик затлар тормышына, сәламәтлегенә, физик һәм юридик затлар мөлкәтенә китерелергә мөмкин булган зыянның исәп-хисабын килештерү тәртибен раслау турында

«Гидротехника корылмалары иминлеге турында» 1997 елның 21 июлендәге 117- ФЗ номерлы Федераль закон һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Гидротехника корылмасы һәлакәте аркасында китерелгән зыян өчен гражданлык җаваплылыгын финанслар белән тәэмин итү күләмен билгеләү кагыйдәләрен раслау турында» 2001 елның 18 декабрендәге 876 нчы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу механизм карарга теркәлгән Татарстан Республикасы территориясендә гидротехника корылмасы һәлакәте аркасында физик затлар тормышына, сәламәтлегенә, физик һәм юридик затлар мөлкәтенә китерелергә мөмкин булган зыянның исәп-хисабын килештерү тәртибен расларга.

2. Түбәндәгеләр үз көчен югалткан дип санарга:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Гидротехника корылмасы һәлакәте аркасында Татарстан Республикасы территориясендә физик затлар тормышына, сәламәтлегенә, физик һәм юридик затлар мөлкәтенә китерелергә мөмкин булган зыянның исәп-хисабын килештерү тәртибен раслау турында» 2010 ел, 25 гыйнвар, 40 нчы карары;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Гидротехника корылмасы һәлакәте аркасында Татарстан Республикасы территориясендә физик затлар тормышына, сәламәтлегенә, физик һәм юридик затлар мөлкәтенә китерелергә мөмкин булган зыянның исәп-хисабын килештерү тәртибен раслау турында»

2010 ел, 25 гыйнвар, 40 нчы карарына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 ел, 22 июль, 579 нчы карары;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 ел, 26 ноябрь, 938 нче карарының 3 нче пункты;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер актларына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2012 ел, 30 июль, 646 нчы карарының 8 нче пункты.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2019 ел, 9 декабрь, 1124 нче
карары белән расланды

# Татарстан Республикасы территориясендә гидротехника корылмасы һәлакәте аркасында физик затлар тормышына, сәламәтлегенә, физик һәм юридик затлар мөлкәтенә китерелергә мөмкин булган зыянның исәп-хисабын килештерү тәртибе

1. Бу Тәртип «Гидротехника корылмалары иминлеге турында» 1997 елның 21 июлендәге 117-ФЗ номерлы Федераль закон һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Гидротехника корылмасы һәлакәте аркасында китерелгән зыян өчен гражданлык җаваплылыгын финанслар белән тәэмин итү күләмен билгеләү кагыйдәләрен раслау турында» 2001 елның 18 декабрендәге 876 номерлы карары нигезендә эшләнде һәм Татарстан Республикасы территориясендә гидротехника корылмасы һәлакәте аркасында физик затлар тормышына, сәламәтлегенә, физик һәм юридик затлар мөлкәтенә китерелергә мөмкин булган зыянның исәп-хисабын килештерү (алга таба – китерелергә мөмкин булган зыянның исәп-хисабы) процедурасын регламентлаштыра.

2. Китерелергә мөмкин булган зыянның исәп-хисабы гидротехника корылмасының хуҗасы тарафыннан түбәндәгеләр нигезендә башкарыла:

Россия Федерациясе Гражданнар оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигый бәла-казалар салган зыяннарны бетерү министрлыгының, Россия Федерациясе Энергетика министрлыгының, Россия Федерациясе Табигый байлыклар министрлыгының, Россия Федерациясе Транспорт министрлыгының, Россия Федерациясенең Федераль тау һәм сәнәгать күзәтчелегенең 2002 елның 18 маендагы 243/150/270/68/89 номерлы уртак боерыгы белән расланган Гидротехника корылмасы һәлакәте аркасында юридик затлар тормышына, сәламәтлегенә, физик һәм юридик затлар мөлкәтенә китерелергә мөмкин булган зыян күләмен билгеләү тәртибе;

Федераль экологик, технологик һәм атом күзәтчелеге хезмәтенең «Гидротехника корылмасы һәлакәте аркасында (суднолар йөри торган һәм порт гидротехника корылмаларыннан тыш) физик затларның тормышына, сәламәтлегенә, физик һәм юридик затларның мөлкәтенә китерелергә мөмкин булган зыян күләмен билгеләү методикасын раслау турында» 2016 елның 29 мартындагы 120 номерлы боерыгы белән расланган зыян күләмен билгеләү методикасы;

Россия Федерациясе Гражданнар оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигый бәла-казалар салган зыяннарны бетерү министрлыгының һәм Россия Федерациясе Транспорт министрлыгының 2007 елның 2 октябрендәге 528/143 номерлы уртак боерыгы белән расланган Суднолар йөри торган гидротехника корылмалары һәлакәте аркасында китерелергә мөмкин булган зыянның исәп-хисабын башкару методикасы.

3. Китерелергә мөмкин булган зыянның исәп-хисабын килештерү өчен гидротехника корылмасы хуҗасы Татарстан Республикасы Экология һәм табигый байлыклар министрлыгына (алга таба – Министрлык) түбәндәгеләрне кертә:

китерелергә мөмкин булган зыянның исәп-хисабын килештерү турында гариза;

китерелергә мөмкин булган зыянның бу Тәртипнең 2 нче пунктында күрсәтелгән норматив хокукый актлар нигезендә башкарылган, кәгазь чыганакта өч нөсхәдә булган исәп-хисабын;

китерелергә мөмкин булган зыянның электрон чыганакта булган исәп-хисабын.

4. Гидротехника корылмасы хуҗасы китерелергә мөмкин булган зыянның исәп-хисабы һәм тапшырыла торган мәгълүматларның дөреслеге өчен җавап бирә.

5. Министрлык бу Тәртипнең 3 нче пункты белән күздә тотылган документлар кергән вакыттан биш көн эчендә электрон документ формасындагы китерелергә мөмкин булган зыянның исәп-хисабын, Татарстан Республикасы электрон документлар әйләнешенең бердәм ведомствоара системасыннан файдаланып, Татарстан Республикасының башкарма хакимият органнарына, нинди тармакка каравыннан чыгып, зыян төрләре буенча фаразларны карап тикшерү өчен җибәрә:

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгына – торак фондына китерелгән зыянның, су белән тәэмин итү бозылу аркасында китерелгән зыянның исәп-хисабын карау һәм тикшерү өчен;

Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгына – транспорт элементларына китерелгән зыянның исәп-хисабын карау һәм тикшерү өчен;

Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгына – элемтә элементларына китерелгән зыянның исәп-хисабын карау һәм тикшерү өчен;

Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгына –урманны чимал буларак югалтудан, шулай ук урманнарны су басудан һәм алар һәлак булудан урман фондына китерелгән зыянның исәп-хисабын карау һәм тикшерү өчен;

Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгына – предприятиеләрнең төп һәм әйләнеш фондларына китерелгән зыянның, предприятиеләрнең әзер продукциясенә китерелгән зыянның исәп-хисабын карау һәм тикшерү өчен;

Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгына – авыл хуҗалыгы җитештерүенә китерелгән зыянның исәп-хисабын карау һәм тикшерү өчен;

Татарстан Республикасының Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетына – балык хуҗалыгына китерелгән зыянның исәп-хисабын карау һәм тикшерү өчен.

6. Министрлык бу Тәртипнең 5 нче пункты белән күздә тотылган вакыт эчендә табигый мохиткә китерелгән зыянның исәп-хисабын карый һәм тикшерә.

7. Бу Тәртипнең 5 нче пунктында күрсәтелгән Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары 15 көн эчендә китерелергә мөмкин булган зыянның исәп-хисабын килештерү яки килештерүдән баш тарту мөмкинлеге турындагы

бәяләмәне, Татарстан Республикасы электрон документлар әйләнешенең бердәм ведомствоара системасыннан файдаланып, Министрлыкка җибәрә.

8. Министрлык бәяләмәләрне алган көннән эш көннәрендә исәпләнә торган биш көн эчендә:

Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары тарафыннан кертелгән бәяләмәләрне берләштерә;

китерелергә мөмкин булган зыянның исәп-хисабын килештерү яки килештерүдән баш тарту турында карар кабул итә.

9. Китерелергә мөмкин булган зыянның исәп-хисабын килештерү турында карар кабул ителгән очракта, китерелергә мөмкин булган зыянның исәп-хисабы титул битенең барлык нөсхәләренә Министрлыкның вазыйфаи заты тарафыннан килештерү турында билге куела һәм герб мөһере белән раслана.

10. Гидротехника корылмасының хуҗасына китерелергә мөмкин булган зыянның исәп-хисабын килештерү турындагы карар кабул ителгән көннән эш көннәрендә исәпләнә торган өч көн эчендә китерелергә мөмкин булган зыянның исәп-хисабы өч нөсхәдә кире кайтарыла.

11. Китерелергә мөмкин булган зыянның исәп-хисабын килештерүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез булып тора:

китерелергә мөмкин булган зыянның тәкъдим ителгән исәп-хисабы бу Тәртипнең 2 нче пунктында күрсәтелгән норматив хокукый актлар таләпләренә туры килмәү;

тапшырылган документларда дөрес, тулы булмаган, ялган мәгълүмат булу;

бу Тәртипнең 5 нче пунктында күрсәтелгән Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары тарафыннан китерелергә мөмкин булган зыянның исәп-хисабын килештерүдән баш тарту.

12. Китерелергә мөмкин булган зыянның исәп-хисабын килештерүдән баш тарту турындагы карар, баш тарту сәбәпләрен күрсәтеп, Министрлык хаты белән рәсмиләштерелә, министр урынбасары тарафыннан имзалана, баш тарту турында карар кабул ителгән көннән эш көннәрендә исәпләнә торган өч көн эчендә гидротехника корылмасының хуҗасына җибәрелә.

13. Министрлык китерелергә мөмкин булган зыянның исәп-хисабын килештерү буенча материалларының исәбен алып бара һәм аларны саклый. Материалларны саклау вакыты – 5 ел.

___